Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының унтугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

10 октябрь, 2022 ел

№ 63

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Питрәч муниципаль районы Званка һәм Кощаково авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында 2011 елның 30 июнендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге уставы нигезендә **Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалтуын таныырга:

- «Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлеге советына гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 28 февралендәге 4а номерлы;
- «Званка авыл җирлегенең ревизия комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 16 октябрендәге 19 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлеге территориясендә гражданнарга милеккә бирелә торган яисә арендага бирелә торган җир участокларының иң чик күләмнәре турында» 2006 елның 16 октябрендәге 20 номерлы;
- «Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары һәм муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына өчен айлык өстәмә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 10 гыйнварындагы 1а номерлы;
- «Званка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 2 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлеге Советы эшенең регламенты турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы;
- ТР Питрәч муниципаль районы Званка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2010 елның 16 мартындагы 13 номерлы;

- «Җир салымы турында» 2010 елның 3 ноябрендәге, 9 номерлы (Питрәч муниципаль районы «Званка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2011 елның 26 апрелендәге 11 номерлы карары редакциясендә);

- «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Званка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 гыйнварындагы 3 номерлы карары;

- «Званка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2010 елның 3 ноябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 26 апрелендәге 11 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова